# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Лебедино авыл җирлеге составына керүче Новопасск авылы

10 ноябрь 2020 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлеге составына керүче Новопасск торак пунктында гражданнар җыены

**Карар итте**:

1. 2021 елда Лебедино авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булмаган кешедән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге чараларга юнәлдерергә:
 - авыл эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту, вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча хезмәт өчен түләү);
 - техниканы – тракторны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт өчен түләү);
 - авыл җирлегенең торак пунктында урамнарны яктырту (урам фонарьлары сатып алу, СИП үткәргеч сатып алу, килешү буенча хезмәт өчен түләү);
 - җирлек территориясен төзекләндерү (каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу);
 - мәдәни мирас һәйкәлләрен саклау һәм карап тоту (төзелеш материаллары, буяулар, триммерлар сатып алу);
 - мәдәният һәм ялны оештыру өчен шартлар тудыру (музыка җиһазлары, экранлы мультимедиа проекторы, өстәл уеннары – шахмат, шашка, сатып алу).

3. Әлеге карарны Лебедино авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Новоспасск авылы, Некрасов урамы, 18 йорт, адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Лебедино авыл җирлеге башлыгы** **Ю.И. Тюкарев**